А. ФАДЕЕВ

МЕТЕЛИЦА



ТАТГОСИЗДАТ — 1952

МӘКТӘП КӨТЕПХАНӘСЕ

А. ФАДЕЕВ

МЕТЕЛИЦА

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ РЕДАКЦИЯСЕ
КАЗАН 1952

* * *

Җаваплы редакторы
К. КОТДУСОВА

Тышлык художнигы
Э. ДЬЯЧКОВА

* * *

А. ФАДЕЕВ

МЕТЕЛИЦА

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе *А. Шамов*

Художество редакторы *Ш. Мөхәммәтҗанов*

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*

Корректоры *И. Уразова*

Наборга бирелде 24/XI-1951 ел. Басарга кул куелды 12/I-1952 ел. ПФ 02505.
Кәгазь форматы 84×108 1/32-0,38 к. т. Учет-изд. 0,91 таб. Басма табак 1,23.
Табакта 44000 хәреф. Заказ № 0374. Тираж 5000+65.

ТАССР Министрлар Советы янындагы Полиграфия промышленносте,
издательстволар һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Татполиграф типографиясе
Казан, Миславский ур., йорт 9.

1

Август башлары иде. Юеш һавалы төн уртасында Левинсон отрядына атлы эстафета[1] килде. Аны партизан отрядларының штаб начальнигы Суховей-Ковтун карт җибәргән иде. Суховей-Ковтун карт партизан отрядларының төп көчләренә японнарның һөҗүм итүләре, Известка янында бик каты сугышлар булуы, үзенең, тугыз пуля белән яраланып, хәзер аучылар кышлагында яшеренеп ятуы турында язган иде.

Левинсон бу эстафетаны төнлә сәгать беренче яртыда алды, ә ярты сәгатьтән соң инде көтүче Метелицаның атлы взводы, куркыныч хәбәрне тарата-тарата, юллар буйлап сибелеп чаба иде.

Левинсон, бик ерак, тын урыннарга үтеп кереп, башка отрядлар белән бәйләнешен бөтенләй диярлек югалтты. Ул үзенең партизаннарын тайганың күп еллар буенча кеше аяк басмаган сукмаклары буйлап алып бара иде.

Бөтен Уланхин яланын японнар белән колчакчылар басып алганнар. Дошман күзәтчеләре барлык юнәлешләрдә йөриләр, алар Левинсон дозорларына әллә ничә тапкыр очраганнар иде инде.

Таң вакытында тау ягыннан Левинсонның юлын кистеләр, ләкин ул, ике сәгать сугышканнан соң, утызлап кешесен югалтып, дошман от-

[1] Эстафета — бу урында ашыгыч хәбәр мәгънәсендә.

рядлары аркылы бәреп үтте. Хәзер Колчакның атлы гаскәре, аның эзенә басып, куып килә.

— Барыбер бу районда моннан соң калуның мәгънәсе юк, — диде Левинсон, күңелсезләнеп. — Бердәнбер юл — төньякка. — Ул, кыр сумкасын ачып, картасын чыгарды. — Менә... монда тау сыртлары буйлап үтәргә була... Ерагын ерак, ләкин ни эшләмәк кирәк...

Левинсон төнне тайгада уздырырга булды. Ул, алдан разведчиклар җибәреп, юлны капшап карарга, икмәккә һәм атларга бай булган Тудо-Ваки үзәнлегенә барып чыгарга өметләнә иде.

— Разведкага Метелица барыр, төнне монда уздырырбыз, — диде Левинсон үзенең ярдәмчесе Баклановка һәм шул турыда тиешле боерыклар бирде.

— О-ой... тукта-а!.. — дип кычкырдылар алда. Аваз цепь буенча тапшырылды, һәм алдагылар туктаган вакытта, арттагылар килеп өелешүләрендә дәвам иттеләр.

— Метелица!

— Метелицаны чакыралар... — дигән аваз тагын цепь буенча йөгереп узды.

Берничә секундтан соң, Метелица, ат өстендә, карчыгадай бөгелеп, чабып узды һәм бөтен отряд аның атка көтүчеләрчә оста атланганын горурланып карап калды.

Метелицаны разведкага җибәргәндә, Левинсон аңа, ничек кенә булса да, бүген төнлә белән әйләнеп кайтырга кушты.

Метелица отрядтан төштән соң сәгать дүртләрдә чыгып китте, һәм айгырын бик каты куды. Ул тайгадан чыкканда инде бөтенләй караңгы төшкән иде. Ул атын түбәсе ишелеп төшкән, иске һәм черегән бер омшаник[1] янында туктатты.

[1] Омшаник — мүкләп салынган келәт.

Метелица атын бәйләде һәм, орыну белән үк таралып китәргә торган черек бура чатына ябыша-ябыша, караңгы тишеккә төшеп киту куркынычы астында, почмак өстенә үрмәләп менде. Ул, аякларын кәкрәйтеп, бүрәнәләргә баса-баса югары менгәннән соң, күзләрен караңгыга текәп һәм колак салып, тын да алмыйча, бер ун минутлап торды.

Аннары ул иярена сикерде һәм яңадан юлга чыкты. Бу юл буйлап күптән йөрелмәгәнгә күрә, арба эзләре үлән арасыннан чак кына беленеп тора иде. Нечкә каеннар караңгыда, сүнгән шәмнәр төсле, тонык кына күренәләр.

Ул калкулык өстенә менде: сул якта кара сопкалар[1], гигант ерткыч сырты кебек бөкрәеп, сузылып ята; елга шаулый; ике чакрым чамасы ераклыкта, елга буенда ук булырга кирәк, бер учак яна; аннан арырак, юлны кисеп үтеп, авылның саргылт утлары тезелеп киткән.

Метелица туңа башлады: өстенә ул төймәләре өзелгән, якасы ачылып торган гимнастерка, ә аның өстеннән солдат фуфайкасы кигән һәм аның да якасын чишеп җибәргән иде. Башлап ул ут янына барырга булды. Кирәк булса-нитсә дип, револьверын, кобурасыннан чыгарып, фуфайка астындагы каешына кыстырды, ә кобурасын ияр артындагы сумкага тыкты.

Ул инде учакка бөтенләй якынлашкан иде, — кинәт караңгыда ниндидер бер ат борчылып кешнәп җибәрде. Метелицаның айгыры ашкынып куйды һәм, бөтен гәүдәсе белән калтырап, колакларын торгызып, җавап кайтарды. Шул ук секундта учак янында бер шәүлә кыймылдады.

---

[1] Сопка — урмансыз түбәле тау.

Метелица атына камчысы белән бар хәлгә сукты һәм аты белән бергә үрә торды.

Учак янында, кара башлы, ябык кына бер малай, куркынган күзләрен акайтып, бер кулына чыбыркысын тотып, салынып төшкән җиңле икенче кулын һөҗүмнән саклаңган шикелле югары күтәреп, басып тора иде. Аягында чабата, өстендә зур иске пиджак, ертык чалбар. Билен сүс бау белән буган. Метелица айгырын малай янына ук китереп туктатты һәм аны чак кына таптатмады. Ертык тезле бу малайның куркуы күзләренә чыккан һәм хуҗасы биргән иске, ертык пиджак эченнән аның, гаепле һәм кызганыч булып, балаларча нечкә муены күренеп тора.

Метелица аңа:

— Нигә басып торасың? — диде. — Шүрләдеңме әллә?.. Ах син, чыпчык, чыпчык, — юләр дә соң! Баскан да каткан! Әгәр мин сине таптаткан булсам?..

Малай, куркуыннан чак кына тынын алып:

— Ә нәрсә дип син үзең шайтан кебек минем өскә килеп чыктың? — диде. — Куркырсың да шул — минем монда атларым бар...

Метелица көлемсерәп сузып:

— Атла-арың ба-ар? — диде. — Кара син аны! — Ул биленә таянды, гәүдәсен артка ташлады һәм кинәт көлеп җибәрде.

Малай, ышанмыйча, уңайсызланып, борынын тартып куйды, ләкин бер дә куркыныч нәрсә юк икәнен, ә, киресенчә, гаҗәп кызык, күңелле хәлгә очравын сизеп, маңгаен шундый җыерды, хәтта борыны югары күтәрелде һәм бөтенләй балаларча, нечкә, шаян тавыш белән көләргә тотынды. Метелица бу көтелмәгән хәлдән тагын да катырак шаркылдады, аннары алар икесе дә, бер-берсен ирексез көлдереп, шулай берничә

минут көлештеләр: Метелица иярендә утырган килеш, ут яктысында тешләрен ялтыратып бер артка, бер алга чайкалып көлә, ә малай, җиргә куллары белән таянып утырып, пырхылдаган саен бөтен гәүдәсе белән артка ташлана иде.

Ахырда, Метелица, өзәнгедән аягын чыгара-чыгара:

— Ай-яй, көлдереп эчне катырдың да соң! — диде. — Кызык малай икәнсең, чынлап та... — Аннары ул, атыннан сикереп төшеп, кулларын утка таба сузды.

Малай, көлүеннән туктап, тагын да кызык нәрсә көткәндәй, аңа таба җитди йөз белән шатланып карап тора иде. Аннары ул, үзенең күзәтүләренә соңгы йомгак ясагандай:

— Бик күңелле кеше икәнсең үзең, шайтан! — диде.

Метелица көлемсерәде:

— Минме? Мин, туган, шундый күңелле кеше инде...

— Ә мин синнән бик курыктым, — дип, малай яшерми әйтеп бирде. — Монда атларым бар минем. Ә мин бәрәңге пешерәдер идем...

— Бәрәңге? Менә бусы шәп! — Метелица, кулыннан тезгенен җибәрмичә генә, малай янына утырды. — Каян аласың соң син аны, бәрәңгене?

— Менә сиңа кирәк булса, каян аласың, имеш... Монда ул бетәсе түгел! — дип, малай куллары белән тирә-якны күрсәтте.

— Димәк, урлыйсың?

— Урлыйм... Бир әле атыңны, үзем тотып торыйм... Юк, туган, ычкындырмам, курыкма. — Малай, айгырның суырылып кергән эчен, чибәр, ябык һәм мускуллы фигурасын үзенең тәҗрибәле күзләре белән карап: — Әйбәт айгыр икән, — диде. — Ә син үзең кайдан соң?

— Айгырым зарарсыз, — диде Метелица. — Ә син кайдан?

Малай утларга таба күрсәтте:

— Әнә аннан. Безнең Ханихеза авылы ул... Йөз егерме йортлы...

— Шулай... Ә мин тау артындагы Воробьевкадан. Бәлки, ишеткәнең дә бардыр?

— Воробьевкадан? Юк, ишеткәнем юк — ерак булса кирәк...

— Ерак.

— Ә безгә нигә килеп чыктың?

— Ничек дип әйтергә инде аны... Моны, туган, сөйләп торуы бик озак... Сезнең авылдан атлар сатып алырга уйлыйм мин; сездә атлар бик күп, дип сөйлиләр... Мин, туган, атларны бик яратам, — диде Метелица, бик хәйләле генә итеп, — гомер буе ат көтүе көттем, тик шунсы — үз атларым түгел иде.

— Ә мин үз атларымны көтәм дип уйлыйсыңмы әллә? Хуҗа атлары...

Малай, үзенең каралып беткән ябык кулын җиң очыннан чыгарып, чыбыркы сабы белән көлне актарырга тотынды; аннан, матур гына тәгәрәп, авыз суын китереп, кара бәрәңгеләр килеп чыкты.

— Бәлки, синең ашыйсың киләдер? — диде малай. — Минем ипи дә бар, тик күп түгел...

Метелица:

— Рәхмәт, мин әле генә ашаган идем — менә моннан! — дип, бугазына кадәр тулган икәнен күрсәтте.

Малай бәрәңгене урталай сындырды да, аңа бераз өргәләп, яртысын кабыгы-ние белән кабып җибәрде, теле өстендә әвәләп торды һәм, нечкә колакларын селкетә-селкетә, бик тәмләп чәйнәргә тотынды. Чәйнәп бетергәч, Метелицага карады:

— Ятим мин, ятим калганга ярты ел була инде менә, — диде. — Әтине казаклар үтерде, әнине дә үтерделәр, шулай ук абыйны да...

— Казаклармы? — дип, Метелица кинәт селкенеп куйды.

— Ә кем булсын тагы? Харап күп кешене үтерде алар. Йортыбызны да яндырдылар, әле безнекен генә түгел, уникеләп йортны. Ай саен килеп чыгалар, хәзер дә менә кырыклап кеше тора. Ә безнең арттагы волостьлы авылда, Ракитноеда, анда инде бер полк бөтен җәй буе тора. Ух, явызланалар да соң! Ал инде бәрәңгене, аша...

— Ничек соң сез алай — качмыйсыз дамы?.. Әнә урманыгыз нинди бит... — диде Метелица, хәтта урыныннан аз гына күтәрелеп тә куйды.

— Урман булса ни? Урманда гомер буе яшәп булмый. Аннары, анда сазлык бит безнең — керсәң, чыга да алмассың — шундый упкын анда...

— Менә нәрсә, — диде Метелица, урыныннан тора-тора, — атымны карап тор әле син, ә мин авылга барып килим. Күрәм, монда сезнең ат сатып алу түгел, хәтта актык атыңны да тартып алырлар...

Малай кинәт күңелсезләнде:

— Нәрсәгә бик тиз китәсең әле? Утыр инде... — диде һәм урыныннан торды. Метелицага үзенең ялынулы, дымлы зур күзләре белән карап, кызганыч тавыш белән аңлатып бирде: — Күңелсез миңа монда үзем генә...

— Ярамый, туган, — дип, Метелица кулларын җәеп җибәрде. — Караңгы чагында караштыргалап калырга кирәк... Мин бик тиз әйләнеп кайтам, ә айгырны тышаулыйк... Аларның иң главныйлары кайсы йортта тора?

Малай эскадрон начальнигы торган йортны ничек табарга һәм аңа бакчалар артыннан ничек барырга икәнен өйрәтте.

— Ә этләр күпме сездә?

— Этләр — җитәрлек, тик алар усал түгел.

Метелица, айгырын тышаулап, малай белән саубуллашты да, елга буендагы сукмак буенча китте. Ул караңгыга кереп күздән югалганчы, малай аның артыннан кайгылы йөз белән карап калды.

2

Ярты сәгатьтән соң инде Метелица авыл янында иде. Сукмак уңга борылды, ләкин Метелица, көтүче малайның киңәше буенча, бакча киртәләренә барып төртелгәнче, чабылган болын белән барды.

Авыл йоклый иде инде; утлар сүнгән, йолдызлар яктысында кечкенә генә өйләрнең салам түбәләре беленер-беленмәс кенә күренәләр.

Метелица, ике тыкрыкны үтеп, өченчесенә борылды. Этләр, курыккан кебек өрә-өрә, аны озатып калдылар, ләкин урамга беркем дә чыкмады, аңа беркем дә эндәшмәде. Ул тагын берничә тыкрыкны үтте һәм, ниһаять, поп бакчасының буяулы коймасы янына барып чыкты. Метелица, як-ягына каранып, бераз тыңлап торды һәм, шикләнерлек нәрсә тапмагач, тавышсыз чыгармыйча, тиз генә койма аша сикерде.

Бакча куе, агачлар күп, ләкин инде яфраклар коелган. Метелица тын да алмыйча диярлек бакча эченә үтте. Куе вак агачлар кинәт бетте, сул як тәрәзәдә ут күренде. Тәрәзә ачык. Өй эчендә кешеләр утыра. Җиргә коелган яфраклар өстенә тигез, йомшак якты төшкән, тирә-яклары яктыртылган алмагачлар алтын төсле ялтырап торалар.

Бүлмә эчендә дүрт кеше, түрдәге өстәл тирәсенә утырып, карта уйный иде. Уң якта тәбәнәк буйлы, уйнаклап торган күзле, чәчен майлап тараган карт поп утыра; ул өстәл өстендәге карталарны ябык, кечкенә кулы белән җитез генә ала һәм аларны уенчыктай кыска бармаклары белән тын гына аралаштыра. Авызына трубка капкан, матур, тулы гәүдәле бер офицер, тәрәзәгә таба карап, Метелицага таба йөзе белән утырган. Метелица аны эскадрон начальнигыдыр дип уйлады. Сул якта башына кара папаха, өстенә погонсыз бурка кигән икенче офицер утырган, ул картаны өстәлгә ташлаган саен буркасына төренә.

Метелица, иелеп, яны белән чигенә-чигенә, тәрәзә яныннан китте. Ул аркылыга сузылган аллеяга борылган гына иде, шинелен бер иңбашына гына салган бер кеше белән йөзгә-йөз килеп бәрелде; аның артында тагын ике кеше бар иде.

Метелицага килеп бәрелгән кеше, бәрелгәндә чак кына төшми калган шинелен тотып, гаҗәпләнеп:

— Син ни эшлисең монда? — дип сорады.

Метелица бер читкә сикерде һәм куаклар арасына ташланды.

— Тукта! Тотыгыз аны! Тот! Монда!.. Әй!.. — дип, берьюлы берничә кеше кычкырып җибәрде. Аның артында револьвердан аткан тавышлар бик каты яңгырады.

Метелица, куаклар арасында буталып, фуражкасын югалтып, тәвәккәлләп алга йөгерде, ләкин инде тавышлар кайдадыр алдан ишетелә, ә урамда котырынып эт өрә иде.

Кайсыдыр, кулын сузып, Метелицага таба ташланды:

— Менә ул, тот! — дип кычкырды. Пуля колак төбеннән үк сызгырып үтте.

Метелица да атты. Аның өстенә йөгереп килгән кеше сөртенеп егылды.

Үзенең эләгүенә актык минутка кадәр һич тә ышанмаган Метелица тантаналы тавыш белән әйтте:

— Юк, тота алмассың...

Ләкин зур һәм авыр гәүдәле берәү арттан аның өстенә сикерде, аны егып, басып ятты. Метелица кулын ычкындырырга тырышты, ләкин башына бик каты сугылгач, миңгерәп китте...

Аннары аны туктаусыз кыйнадылар, хәтта ул, аңын югалткач та, аларның кыйнаганнарын тойды...

3

Левинсон отряды йоклаган үзәнлектә бераз караңгы һәм юеш иде, ләкин Хаунихедза артындагы кызгылт сары аралыктан инде кояш карый һәм тайга өстендә көн башланган иде.

Атлар янында йокымсырап утырган дневальный йокы аралаш, еракта пулемёт такылдаган шикелле, үткер, өзлексез тавышлар ишетте һәм, винтовкасын тотып, сикереп торды. Ләкин бу елга буендагы зирек агачын тукран чукыган тавыш кына иде.

Дневальный сүгенеп алды һәм, салкыннан бөрешеп, ертык шинеленә ныграк төренеп, ачыклыкка чыкты.

„Ә Метелица һаман юк... Күрәсең, тыгынып, нинди дә булса бер өйдә изрәп йоклый торгандыр, ә син монда ашамаган килеш утыр“, — дип уйлады ул.

Дневальный, Левинсонны борчырга теләмичә, аның ярдәмчесе булган Баклановны уятты.

Бакланов, йокы аралаш бернәрсә дә аңламыйча, күзләрен акайтып, урыныннан кузгалды.

— Нәрсә?.. Кайтмадымы? — дип, ул, йокы белән исергән күзләрен көчкә-көчкә ачып, бернәрсә дә төшенмәстән кымшана башлады. — Ничек кайтмасын ди? Юк, син, туган, ташла, аның кайтмавы мөмкин түгел!.. Ах, әйе! Я, алайса, уят Левинсонны. — Ул урыныннан сикереп торды, бик тиз генә каешын буды һәм кашларын җыерды.

Левинсон, никадәр каты йоклаган булса да, үз фамилиясен ишетү белән үк күзләрен ачты, торып утырды. Дневальныйга һәм Баклановка карап алу белән үк ул Метелицаның әле кайтмаганлыгын һәм отрядка юлга чыгарга күптән вакыт икәнен аңлады. Шул минутта ук ул, җиргә тезләнеп, шинелен дугалап төрә-төрә, Баклановның куркынулы сорауларына җавап бирә иде инде.

— Я, әллә ни булмаган бит? Мин шулай булыр дип уйлаган да идем... Билгеле, без аны юлда очратырбыз.

— Әгәр очратмасак?

— Әгәр очратмасакмы?.. Кара әле, шинельне бәйләрлек запас җеп кисәге юкмы синең?

Дневальный йоклап яткан кешеләргә аягы белән төртә-төртә кычкырды:

— Тор, тор, ялкау! Даешь авылга!

Үлән арасыннан партизаннарның тузгыган башлары күтәрелә иде.

Метелицаның дошман кулына эләгү мөмкинлеге турындагы фикер кешеләрнең башына бик авыр урнашты. Һәр партизан бу фикерне курка-курка гына үз башыннан куарга тырышты. Киресенчә, дневальныйның „взводный, тыгынып, нинди дә булса бер өйдә изрәп йоклый

торгандыр“, дигән фикеренә, — йомышны бик тиз һәм оста үтәүчән Метелицага бу сыйфат һич тә хас булмаса да, — кушылучылар артканнан-арта барды. Күпләр Метелицаның „әшәкелегеннән һәм аңсызлыгыннан“ ачыктан-ачык зарландылар һәм, хәзер үк аңа каршы юлга чыгарга кирәклекне әйтеп, Левинсонны туйдырып бетерделәр. Левинсон, ниһаять, юлга чыгарга приказ биргәч, отряд шундый шатланды, әйтерсең, бу приказ белән аларның чынлап та бөтен бәлаләре, бөтен интегүләре бетә иде инде.

Алар бер-ике сәгать бардылар, ә сумала төсле кара, бөдрә чәчле взводный һаман күренми иде әле.

Алар тагын бер-ике сәгать бардылар, ә Метелица һаман юк иде. Отряд тайга башланып киткән урынга авыр, тирән тынлык эчендә якынлашты.

4

Метелица зур, караңгы сарайда аңына килде, — ул юеш җир өстендә ята иде. Ул нәрсә булганын кинәт исенә төшерде. Кыйналудан аның башы әле һаман шаулый, чәчләре кан белән берегеп каткан, — маңгаенда да, яңакларында да кан оешып каткан иде.

Аның башына килгән беренче фикер, — качып булмасмы икән, дигән фикер булды. Ул бөтен сарайны актарып чыкты, бөтен тишекләрне капшап карады, хәтта ишекне җимерергә дә маташты. Ул һәр урында да салкын агачка барып төртелде, ә ярыклар шулкадәр кечкенә, хәтта аннан карап та булмый, — алар күзгә таң яктысын да бик авырлык белән генә үткәрәләр иде.

Метелица сарайны тагын бер кат карап чыгарга өлгермәде, тышта аяк тавышлары ишетелде, ишек биге шыгырдады, һәм, иртәнге соргылт, көчсез яктылык белән бергә, сарай эченә лампаслы чалбардан ике казак килеп керде. Метелица, аякларын җәеп басып, күзләрен кыса төшеп, аларга карады.

Аны күргәч, казаклар, нишләргә белмичә, ишек төбендә таптанып тордылар; арттагысы, тынычсызланып, борынын тартып куйды.

Ниһаять, алдагысы:

— Әйдә, якташ, — диде.

Метелица, үз сүзләнеп башын түбән игән хәлдә, тышка чыкты.

Берникадәр вакыттан соң инде ул, поп бакчасыннан карап торган чагында бүлмә эчендә күргән, үзенә таныш булган, кара папахалы кеше алдында басып тора иде. Шунда ук әлеге матур, тулы гәүдәле офицер, Метелицага ачусыз гына гаҗәпләнеп карап, креслода утыра. Бу офицерны Метелица кечә эскадрон начальнигы дип уйлаган иде. Хәзер ул, аларның икесенә дә җентекләп карагач, эскадрон начальнигы — тулы гәүдәле офицер түгел, ә буркалы офицер икәнен аңлады.

Буркалы офицер, ишек төбендә туктап калган казакларга карап, коры гына:

— Китәргә мөмкин, — диде.

Алар, бер-берсенә уңайсыз төртелешеп, чыгып киттеләр.

Начальник, Метелица алдына туктап һәм аңа туп-туры текәп карап:

— Кичә бакчада ни эшләдең син? — дип, тиз генә сорады.

Метелица, барыбер бернәрсә дә әйтмәсен бөтен торышы белән күрсәтеп, офицерның күз

карашыннан җиңелмичә, бер сүз әйтмичә, атлас шикелле кара кашларын сизелер-сизелмәс кенә сикерткәләп, мыскыллап, аңа туп-туры карап торды.

— Ташла син бу юләрлегеңне, — диде начальник. Бу сүзләрне ул һич тә ачуланмыйча, тавышын күтәрмичә әйтте.

Метелица, юл куючан елмаеп:

— Нәрсә юкка сөйләп торырга? — диде.

Эскадрон начальнигы Метелицаның кан оешып каткан, тынып калган шадра йөзенә берничә секунд җентекләп карап торды.

— Син нәрсә, мондагымы, әллә берәр яктан килеп чыктыңмы?

Метелица, кулларын йодрыклап, кызарып һәм аның өстенә ташланудан үзен чак кына тотып калып, каты итеп җавап кайтарды:

— Ташласана, ваше благородие!..

Бурка кигән кеше, бер адым да артка чигенмичә һәм күзләрен Метелицадан алмыйча, беренче мәртәбә гаҗәпләнеп:

— Оһо! — дип кычкырып куйды. Аннары ул кобурасыннан револьверын чыгарды һәм аның белән Метелицаның борын төбендә селтәнде. Метелица, тәрәзәгә таба борылып, тынып калды.

Шуннан соң аны револьвер белән никадәр куркытсалар да, ирекккә чыгарып җибәрәбез дип вәгъдә итә-итә, дөресне сөйләп бирүен никадәр сорасалар да, ул авызыннан бер сүз дә чыгармады, хәтта сорашучыларга бер тапкыр да борылып карамады.

Сорау алуның иң кызган чагында әкрен генә ишек ачылды, һәм ишектән кемнеңдер зур, куркынган, аңгыра күзле, озын чәчле башы күренде.

— Әһә! — диде эскадрон начальнигы. — Җыелып беттегезмени? Алайса, солдатларга әйт, бу егетне алып чыксыннар.

Шул ук ике казак Метелицаны ишек алдына алып чыкты һәм, аңа ачык капкага таба юл күрсәтеп, аның артыннан китте. Метелица әйләнеп карамады, ләкин әлеге ике офицерның да артыннан килгәнен сизде. Алар чиркәү мәйданына килеп чыктылар. Анда чиркәү старостасының бүрәнә өе янына халык җыелган һәм алар атлы казаклар белән чолганып алынган иде.

Метелица башын күтәрде. Мәйданда төрле төстәге киемле мужиклар, малайлар, киндер юбкалы, куркынган чырайлы хатыннар, башларына чәчәкле ак яулык бәйләгән кызлар, арзанлы рәсемдәге шикелле бизәлгән, җыйнак, чиста, бөдрә чәчле, булдыклы атлылар тын гына басып торалар иде.

Ул халык арасыннан үтте һәм өй янында туктады. Офицерлар, аның яныннан үтеп, өйалды баскычына менделәр.

Эскадрон начальнигы, аңа үз янында урын күрсәтеп:

— Монда, монда мен, — диде.

Метелица, басманы бик җиңел атлап, аның янына менеп басты. Хәзер ул һәммәсенә дә бик яхшы күренә иде. Ул тыгыз тәнле, зифа буйлы, кара чәчле, аягында болан тиресеннән тегелгән ула[1], өстендә фуфайка һәм якасын чишеп җибәргән күлмәк, фуфайкасы астыннан билбавының куе яшел чуклары күренеп тора.

Начальник, үтәли тишеп керә торган очлы күз карашын бер генә секундка, әле бер ке-

---

[1] Ула — аяк киеме.

шегә, әле икенче кешегә төби-төби, бөтен халыкны сөзеп карап чыкты да:

— Кайсыгыз белә бу кешене? — дип сорады.

Аның күз карашы төбәлгән һәр кеше, каушап, күзләрен йомгалап, башын түбән ия иде.

Начальник:

— Берегез дә белмиме? — дип кайтарып сорады. — Без моны хәзер ачыкларбыз... — дип өстәде ул һәм, биеп торган сары айгырга атланган, өстенә озын шинель кигән офицерга таба кулын изәп: — Нечитайло! — дип кычкырды.

Халык, бераз гөрләшеп, дулкынлана башлады, алда басып торганнар артларына әйләнеп карадылар, — анда, башын игәнгә, бары җылы мех бүреге генә күренгән, кара жилетлы берәү халык төркемен ерып килә иде. Ул бер кулы белән юл ача, икенче кулы белән кемнедер сөйрәп килә-килә:

— Юл бирегез, юл бирегез! — дип, тиз-тиз генә әйткәли.

Ахырында, ул өйалды баскычы янына килеп җитте, һәм бар кеше дә аның сөйрәп килгән кешесе — өстенә озын пиджак кигән ябык, кара чәчле бер малай икәнен күреп алды. Малай, куркып, аякларын тери һәм акайган күзләре белән әле Метелицага, әле эскадрон начальнигына карый. Халык шаулабрак дулкынлана башлады, көрсенгән һәм хатын-кызларның тартынып кына сөйләшкән тавышлары ишетелде. Метелица түбәнгә карады һәм кинәт кара чәчле малайның кичә аның атын саклап калган көтүче малае икәнен таныды.

Малайның кулыннан тоткан мужик бүреген салды һәм, начальникка башын иеп:

— Менә минем теге көтүче малаем... — дип, сүз башлады.

Лəкин ул, сүзен тыңламаслар дип куркып булса кирəк, малайга таба иелде дə, Метелицага бармагы белəн төртеп күрсəтте:

— Шушымы ул?

Көтүче малае белəн Метелица берничə секунд бер-берсенə туп-туры карашып тордылар. Аннары малай күзлəрен эскадрон начальнигына күчерде, аннары үзенең кулыннан тоткан мужикка карады, тирəн итеп сулады һəм „түгел“ дип башын чайкады...

Халык чак кына дулкынланып куйды һəм яңадан тынды, яңадан чиркəү старостасы абзарындагы бозауның кыштырдаганы ишетелə башлады...

Мужик, Метелицага бармагы белəн тиз-тиз генə төртеп күрсəтə-күрсəтə, калтыранган ягымлы тавыш белəн:

— Курыкма син, юлəр малай, курыкма,— дип, аны үгетлəвендə дəвам итте.—Шул булмыйча, кем булсын соң инде ул чакта?.. Я, яшермə инде, яшермə, курыкма... А-а кабахəт нəрсə!..—дип, ул, кинəт ачуланып, сүзеннəн туктады һəм бөтен көче белəн малайның кулыннан тартты.—Шул инде, ваше благородие, башка кем булсын тагын? Малай курка гына, башка кем булсын соң инде, аты да иярле, сумкасында кобурасы да бар... Кичə төнлə ул учак янына килеп чыккан: „Атымны карап тор əле“, дигəн, ə үзе авылга киткəн, ə малай көткəн-көткəн дə, яктыргач инде көтеп тормаган, атын авылга алып кайткан, аты иярле, сумкасында кобурасы да бар... Кемнеке булсын инде ул?

— Кем килеп чыккан? Нинди кобура?— диде начальник.

Мужик, тагын да каушый төшеп, бүреген әвәләргә тотынды һәм үзенең көтүче малае иртә белән чит бер атны ничек алып кайтуын, атның иярле икәнен, сумкасында револьвер кобурасы да булуын яңадан тотлыга-тотлыга, буташтырып сөйләп бирде.

— Менә нәрсә икән ул, — дип, сузып куйды эскадрон начальнигы. Малайга таба башы белән ишарә итте: — Танымыйм ди бит ул?.. Хәер, китер әле аны монда, без үзебезчә сорыйк әле аннан.

Малайны, арттан төрткәләп, өйалды баскычы янына китерделәр, ләкин ул, менәргә куркып, туктап калды. Офицер, басмадан йөгереп төшеп, малайның калтырап торган ябык иңбашларыннан эләктереп алды да, үзенә таба тартып, аның куркудан түп-түгәрәк булган күзләренә үзенең үткен һәм куркыныч күзләрен текәде...

Малай, күзләрен акайтып, кинәт елап җибәрде:

— А-а... а!..

Бер хатын, түзә алмыйча:

— Нишләтмәкчеләр инде аны? — дип көрсенеп куйды.

Шул ук секундта житез һәм зифа буйлы берәү өйалды баскычыннан сикерде. Халык, кулларын бутап, өркеп китте, — эскадрон начальнигы бик каты килеп бәрелүдән җиргә егылды...

Матур офицер, аптырап калып, аңгыраланып һәм үзенең дә ата белүен бөтенләй онытып булса кирәк:

— Атыгыз аңа!.. Бу нәрсә инде тагы? — дип, кулларын көчсез рәвештә алга сузды.

Берничә атлы казак, атлары белән кешеләрне таптатып, халык эченә ташланды. Метелица,

бөтен гәүдәсе белән дошманның өстенә ятып, аның бугазыннан эләктереп алырга тырышты, ләкин дошман кара канатларга охшаган буркасын җәеп җибәреп, зур ярканат кебек боргаланды, калтыранган кулы белән каешына ябышты, револьверын чыгарырга маташты. Ахырда, ул кобурасын чиште һәм, Метелица нәкъ аның бугазыннан эләктергән секундта, аңа берничә тапкыр атып җибәрде.

Килеп өлгергән казаклар Метелицаны аякларыннан өстерәгәндә, ул әле үләнгә ябыша, тешләрен шыгырдата, башын күтәрергә тырыша, ләкин хәлсезләнгән башы кире төшә һәм җирдән сөйрәлә иде.

— Нечитайло! — дип кычкырды матур офицер. — Эскадронны җыйнарга!.. — Һәм, начальникның йөзенә карамаска тырышып, әдәпле генә сорады: — Сез дә барасызмы?..

— Әйе.

— Командирга ат бирегез!

Ярты сәгатьтән соң инде казаклар эскадроны, сугышка хәзер булып, авылдан чыкты һәм кичә төнлә Метелица килгән юл буйлап югарыга таба чапты.

5

Бөтен отряд белән бергә бик нык тынычсызланган Бакланов, ахырда, түзмәде:

— Кара әле, мин алдан китим, — диде ул Левинсонга. — Кем белә бит аны, чыннан да!

Ул атын шпоралады һәм үзе уйлаганнан да тизрәк урман кырыена, ташландык омшаник янына барып чыкты. Аңа түбәгә менәргә дә туры килмәде, — ярты чакрымнар чамасы ераклыктагы сырттан иллеләп атлының төшеп килгәне күренде.

Бакланов бераз туктап калды, куаклар арасына кереп яшеренде һәм сырт артыннан яңа отрядлар килеп чыкмасмы икән дип көтте. Ләкин артык беркем дә чыкмады; эскадрон, таркау сафлар белән, атлатып кына килә иде; аларның ат өстендә тигез утырмауларына һәм тирләгән атларның башларын чайкауларына караганда, эскадронның чаптырып килүдән әле генә туктаганлыгы күренеп тора иде.

Бакланов кире борылды һәм урман кырыена чыгып килгән Левинсонга чак бәрелмәде. Левинсон аңа туктарга ишарә итте һәм, аның сөйләгәнен тыңлап бетергәч:

— Күпме? — дип сорады.

— Иллеләп булыр.

— Җәяүлеләрме?

— Юк, атлылар...

Левинсон әкрен генә команда бирде:

— Кубрак, Дубов, атлардан төшәргә! Кубрак — уң флангка, Дубов — сулга...

Левинсон, Метелица взводы белән командовать итүне Баклановка тапшырып, аңа шушы урында калырга кушты да, атыннан төшеп, маузерын чайкый-чайкый, цепь алдыннан китте. Ул цепьне куаклыктан чыгармый гына яткырды, ә үзе бер партизан белән омшаник түбәсенә менде.

Эскадрон бөтенләй якын иде инде. Фуражка кырпуларының һәм лампасларының сарылыгына карап, ул аларның казаклар икәнен белде. Кара бурка кигән командирларын да күреп алды.

— Әйт, монда үрмәләп килсеннәр, — диде ул янындагы партизанга пышылдап кына, — тик кара, аяк өстенә тормасыннар, югыйсә... Я, нәрсә карап торасың? Тизрәк! — дип, ул, кашларын җыерып, партизанны этеп җибәрде.

Эскадрон инде шулкадәр якын иде, ат аягы тавышлары, кешеләрнең әкрен генә сөйләшкәннәре ишетелә, хәтта аерым кешеләрнең йөзләре дә күренә иде.

Левинсон инде аларның йөзләрен — бигрәк тә менә хәзер генә алга чыккан, авызына трубка капкан һәм иярендә бик начар утырган, матур, тулы гәүдәле бер офицерның йөзен ап-ачык күрде.

Левинсон кинәт, нечкә тавыш белән сузып:

— Взво-о-од!.. — дип кычкырып җибәрде. — Пли!

Матур офицер бу тавышның беренче авазларын ишеткәч тә, гаҗәпләнеп, башын күтәрде. Ләкин шул ук секундта аның башыннан фуражкасы очып төште, һәм йөзенә чиктән тыш курку, көчсезлек билгеләре чыкты.

— Пли!.. — дип, Левинсон янадан кычкырды һәм, матур офицерга тидерергә тырышып, атып җибәрде.

Эскадрон айкалды; күбесе — шулар арасында матур офицер да — егылды. Аптырап калган кешеләр һәм үрә торган атлар, берничә секунд бер урында таптандылар; нәрсәдер кычкырдылар, ләкин атыш аркасында бернәрсә дә ишетелмәде. Аннары шул буталчык арасыннан кара папахалы, буркалы берәү аерылып чыкты һәм, биеп торган атын бик каты көчәнеп тыеп тотып, эскадрон алдында шашкасын болгады. Калганнары аңа начар буйсындылар булырга кирәк, — кайберләре инде, атларын камчылап, төркемнән аерылып, качарга ук тотындылар, һәм алар артыннан бөтен эскадрон ташланды.

Партизаннар агачлар арасыннан сикереп чыктылар, аеруча кызып киткәннәре ата-ата казаклар артыннан йөгерделәр.

— Атларны! — дип кычкырды Левинсон. — Бакланов, бирегә!

Бакланов, кулындагы слюда төсле ялтыравык шашкасын аска таба сузып, Левинсон яныннан атылып узып китте, — аның артыннан шашкаларын күтәреп, коралларын яңгыратып, һиһайлап кычкырып, Метелица взводы ташланды.

Сугыш тынгач, казаклар эскадроны, кешеләрен һәм атларын югалта-югалта, каен урманы эченә кереп югалгач, партизаннар Метелицаны эзләп таптылар. Казаклар аны бер зур йорт артындагы тыкрыкка, киртә буена ташлап киткәннәр иде. Метелица яны белән яткан, чәчләре шиңгән күзге үлән белән аралашкан иде.

Авылга иң беренче булып Метелица взводы керде. Кешеләр, атларыннан төшеп, Метелицаның гәүдәсе янына килеп бастылар, ә Бакланов, аның янына тезләнеп, взвод командирының кара чәчле башын саклык белән генә күтәрде.

Алар янына килеп җиткән Левинсон:

— Я, ничек, исәнме? — дип сорады.

Бакланов, җирдән тормыйча, әкрен генә җавап кайтарды:

— Юк, суламый...

Шул вакытта партизаннар арасында көтүче малай күренде. Ул, Метелицаның атын җитәкләп, кешеләрне аралап килә иде.

Кешеләр аңа юл бирделәр.

— Менә ул, аның аты, — диде малай. — Карап торырга кушкан иде... Ә үзе әйләнеп кайтмады... Сезнең ат ул, алыгыз!..

---

30 тиен